**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**17 ноябрь 2023 ел** **№ 10**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Чуаш Мәнҗәсе авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Чуаш Мәнҗәсе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылар, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;
- су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Г.Н. Лизратова